**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Игелек – Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фонды Күзәтчелек советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Игелек – Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фондын төзү турында» 2022 елның 3 февралендәге ПУ-85 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 4 апрелендәге ПУ-232 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреш белән) расланган «Игелек – Доброта» җәмгыятьнең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фондының Күзәтчелек советы (алга таба – Күзәтчелек советы) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Күзәтчелек советы составыннан А.М. Терентьевны чыгарырга;

б) Күзәтчелек советы составына Мөхәрләмов Руслан Роберт улын – Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесен кертергә;

в) Күзәтчелек советы әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Н. Миңнехановның – «Татарстан Республикасы Рәисе, Күзәтчелек советы рәисе»;

Ә.Ә. Сәфәровның – «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары»;

А.К. Шиһабетдиновның – «ТАИФ» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 15 апрель
№ 236